СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.04.2020 Баулы шәһәре № 256

Баулы муниципаль районы муниципаль милекчелегендә булган, өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ия булуга һәм (яисә) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 73 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Баулы муниципаль районы муниципаль милекчелегендә булган, өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыра торган оешмаларга ия булуга һәм (яисә) озак срокка файдалануга (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) бирү өчен, шулай ук, кушымта нигезендә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына түләүле нигездә милекчелеккә бирү максатында билгеләнгән мөлкәт исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Баулы район Советының 2017 елның 12 маендагы «Баулы муниципаль районы муниципаль милекчелегендә булган, өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ия булуга һәм (яки) файдалануга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген раслау турында»гы 106 номерлы карары (Баулы муниципаль районы Советының 2017 елның 25 октябрендәге 134 номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 223 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 243 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, Район Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы
Советының
2020 елның 03.04
кабул ителгән 256
номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль милекчелегендәге, өченче затларның хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт
ИСЕМЛЕГЕ

| № п/п | Мөлкәт атамасы | Төп характеристикалары (мәйданы, озынлыгы һәм башкалар) | Урнашу урыны (адресы) | Балансга тотучы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 2нче административ-хуҗалык бинасы | 160.0 | Кырымсарай авылы, Совет урамы, 26 Б йорт | Кырымсарай авыл җирлеге |
| 2. | "Васькино-Туйралы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе" | 856.4 | Васькино-Туйралы авылы, Мәктәп урамы, 25нче йорт | Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3. | Гараж, литер Г1 1 катлы | 90.5 | Новозареченски бистәсе, Совет урамы, 13нче йорт | Новозареченски авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. | Автоном котельный | 17.8 | Новозареченски бистәсе, Совет урамы, 13нче йорт | Новозареченски авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5. | Склад, литер Г2 1 катлы | 12.3 | Новозареченски бистәсе, Совет урамы, 13нче йорт | Новозареченски авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6. | Модульле котельный бинасы | - | Новозареченски бистәсе, Мәктәп урамы, 10нчы йорт | Новозареченски авыл җирлеге башкарма комитеты |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 7. | Уку остаханәсе бинасы | 125,9 | Новозареченски бистәсе, Мәктәп урамы, 2А йорт | Новозареченск мәктәбе |
| 8. | Конкүреш комбинаты бинасы | 142.8 | Александровка авылы, Совет ур., 17нче йорт | Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 9. | Сәнәгать товарлары кибете бинасы | 185,8 | Александровка авылы, Совет ур., 10 а йорт | Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 10. | Торак булмаган бина (мәктәп) | 495,2 | Хансевәр авылы, К.Маркс урамы, 28нче йорт | Салих авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 11. | Җир участогы (кибет өчен) | 238 | Яңа Чүте авылы, Тукай урамы | Салих авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 12. | Яңа Чүте балалар бакчасы бинасы | 287 | Яңа Чүте авылы, Мәктәп урамы, 1нче йорт | Салих авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 13. | Салих клубы бинасының бер өлеше | 180 | Салих авылы, Калинин урамы, 22 йорт | Салих авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 14. | Җир участогы (кибет өчен) | 147 | Алексеевка авылы | Удмурт Ташлысы авыл җирлеге башкарма комитеты |